**Карар**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урманай авыл җирлеге Советы**

Урманай авылы № 11/134 23 апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына тормышка ашырыла торган чыгымнарның юнәлеше турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында " 2010 ел, 28 март, 233 нче карары, һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында һәм Татарстан Республикасы Азнакай район Советының карары нигезендә 22.04.2019ел № 252-35 "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карары нигезендә

Урманай авыл җирлеге карар чыгарды:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше һәм "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлеше белән билгеләнгән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырыга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Председатель: А.И. Закиров